«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАРЫ

2024 елның 16 августы № 113

«Җир салымы турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 58 номерлы «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 387 статьясындагы 2 пункты, шулай ук «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 36 статьясы нигезендә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кирельск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- җирле үзидарә органнары, су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү объектлары, гомуми файдаланудагы мәйданнар, урамнар, юллар, парклар, аллеялар, яшел утыртмалар, истәлекләр, бәйрәм чараларын үткәрү урыннары, спорт объектлары һәм гомуми файдаланудагы башка объектлар биләгән җир кишәрлекләренә карата җирле бюджеттан финанслана торган бюджет, казна учреждениеләре.».

2. Әлеге карарның 3 статьясындагы 5 абзацы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы , Кирельский авылы, Гагарин ур., 1 йорт (административ бина);
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кирельский авылы, Совхоз мәйданы ур., 13 (китапханә);
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы , Кирельский авылы, Түбән ур., 5( "Каенкай" кибете»);
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы , Ишем авылы, Үзәк ур., 10 (авыл мәдәният йорты),
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы , Мордва Каратае авылы, Үзәк ур., 7 (КФҮ бинасы), әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Кирельск
авыл җирлеге » муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Ф.Я.Зиннатуллин